РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕЩЕРЯКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

24 январь 2023 ел                                        № 4

Карарга үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Буа муниципаль районының Карлы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районының Карлы авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Карлы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2014 елның 08 декабрендәге 18 номерлы карарына (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. «Интернет челтәрендә урнаштырыла торган җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны оештыру» нигезләмәсе бүлеге:

8 абзацны түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аның карамагындагы оешмаларның рәсми сайтларыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә. Башка дәүләт органнарының һәм аларга буйсынучы оешмаларның, шулай ук җирле үзидарә органнарының һәм аларга буйсынучы оешмаларның рәсми сайтларыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына карата таләпләр күрсәтелгән органнар тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә билгеләнә.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) басылып чыгарга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районының Карлы
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе                                        Д.Х. Абдрахманов